ГЛАВА ДЮСЬМЕТЬЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.17, с. Дюсьметьево,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422150

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ДҮСМӘТ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур., 17 нче йорт, Дүсмәт авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422150

тел.(факс): (85563) 2-55-19; e-mail: Dusm.Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

Карар
“26” нчы октябрь,2020 ел.

Постановление
№ 2

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Дүсмәт авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-47 санлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.Дүсмәт авылы мәдәният йорты директоры Петрова Мария Петровнаны Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында 2020 елның 18 ноябрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге башлыгы: О.Н.Павлов